**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.09.2023 Балык Бистәсе штп. № 318пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Балык Бистәсе муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерлык җитәкчеләре һәм белгечләре, муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» 27.05.2019 №181пи карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хакы күләмен арттыру турында» 17.09.2022 ел, №1013 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Шәһәр һәм авыл җирлекләрендә үзәкләштерелгән бухгалтерияләр һәм бухгалтерлар җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәт хакы турында» 09.08.2022 ел, №03-16/5605 хатларын исәпкә алып КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Балык Бистәсе муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерлык җитәкчеләре һәм белгечләре, муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» 27.05.2019 №181пи карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-хуҗалык бүлекләре җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында

нигезләмәнең 4 пунктындагы 3 пунктчасында "ике процент" сүзләрен "унбиш процент" сүзләре белән алыштырырга;

1.2 Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль берәмлекләре Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфасына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында Нигезләмәнең 4 пунктындагы 3 пунктчасында «ике процент» сүзләрен «унбиш процент»сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм үзенең гамәлен 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе И.М. Ногмановага йөкләргә (килешү буенча).

Җитәкче Д.А. Сатдинов